МБОУ «Большебитаманская основная общеобразовательная школа
Высокогорского муниципального района Республики Татарстан»

Согласовано.
Заместитель директора по воспитательной работе
__________Мулекова А.Ф.
«01»___09_____2025 г.

Утверждено.
Директор МБОУ «Большебитаманская ООШ»
____________ Мухарлямов Ф.Г.
от «01»___09.______2025 г.

**РАБОЧАЯ ПРОГРАММА КРУЖКА**

**«КЫЗЫКЛЫ СӘХНӘ»**

ДЛЯ 5-8 КЛАССОВ

(кол-во часов в неделю 4, в год 136 часа)

Составитель: учитель начальных классов Багавиева Н.С.

2025- 2026 г.

## Аңлатма язуы

Программа мәктәпнең үсеш программасы һәм өстәмә белем бирү планы нигезендә төзелә.Түгәрәк эше формасында гамәлгә ашырыла.

Эш программасы 5-8 нче сыйныф укучылары өчен атнага 4 сәгать исәбеннән төзелә. Барлыгы 136 сәгать.

Соңгы елларда республикада татар теленең куллану даирәсе киңәйде, иҗтимагый функциясе көчәйде.

Белем һәм тәрбия бирү бер-берсеннән аерылгысыз. Дәресләрдә алган белемнәрне мәктәптәге түгәрәкләрдә, факультатив дәресләрдә,электив курсларда камилләштерү, тулыландыру һәм ныгыту бүген көнүзәк мәсьәләләрнең берсе.

Баланың мәктәптән нинди шәхес булып чыгуында, киләчәктә нинди һөнәр сайлавында укыту -тәрбия эшенең роле бик зур. Укытучы баланың сәләтен күрә белергә һәм тиешле юнәлеш бирергә тиеш. Тиешле түгәрәккә яздыруның беренче максаты – баладагы мавыгуларны, омтылышларны үстерү, аңа сәләтен табуда һәм камилләштерүдә булышу. Икенче максат – балада эчке табигый көчләрне үстерү.

Балаларының сөйләм телен үстерү дәрестән тыш оештырылган эшләр аша алып барыла.

Балаларның чиста, төзек әдәби телдә сөйләшергә өйрәтү, татар сәнгатенә мәхәббәт тәрбияләү, китап укуга кызыксыну уяту, үзләрендә язу теләге уяту максатыннан түгәрәкләр оештырыла.

**Программаның максаты:**

Балаларның сәнгати һәм эстетик культурасын үстерү,аларга тормышта яхшылык һәм матурлыкны күрергә өйрәтү;

**Бурычлар:**

1)Театр сәнгате белән гомуми таныштыру.
2)Театрга нигез салучылар, танылган артистлар белән таныштыру.
3)Драма әсәрләрен өйрәнүгә теләк уяту.
4)Төрле жанрдагы әсәрләрне сәхнәгә кую аша укучыларның табигатьтән бирелгән сәләтләрен үстерү.
5)Сәхнәдә үзеңне тоту осталыгын, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен камилләштерү.
6) Мәктәп күләмендә оештырылган бәйрәм,тамашаларда актив катнашу.

## Программаның актуальлеге

Федераль дәүләт стандартларын гамәлгә ашыру шартларында мәгариф алдына һәр яктан камил,мөстәкыйль һәм иҗади шәхес тәрбияләү максаты куелды.Укучыларга дәресләрдән тыш өстәмә белем бирү дә заман куйган таләпләрнең берсе. Авторлык программасы әлеге максатка ярашлы шәхесне үстерүгә юнәлдерелгән технология нигезендә эшләнде.

## Түгәрәк эше буенча көтелгән нәтиҗәләр :

-укучы үзен иркен тотарга өйрәнә, психологик яктан ачыла;
-үзенең мавыгуына туры килгән эш белән шөгыльләнә;
-түгәрәктәге укучылар, укытучы белән аралашу вакытында, эчке дөньясында ачыла, аралашу әдәбенә өйрәнә;
-укучы фикерләргә, үз фикерен дәлилләргә өйрәнә;
-сөйләм телен камилләштерә ;

-әхлак һәм зәвык тәрбиясе ала;
-шәхес булып тәрбияләнә, үз урынын таба;
-татар теле һәм әдәбияты буенча белемен тирәнәйтә, кызыксыну уята.

Түгәрәк татар теле һәм әдәбияты программасын кабатларга тиеш түгел.

Түгәрәкнең эш формасы күп төрле, монда укытучының иҗади сәләте зур роль уйный. Китап уку, аның турында фикер алышу, кечкенә докладлар төзү, язучы иҗатын өйрәнү, шигырь укучылар бәйгеләре оештыру, әдәби - музыкаль монтаж әзерләү, музейларга бару, җирле матбугат белән танышу, һ.б. бик күп төрле эш алымнары бар. Түгәрәкләрдә техник чаралар да куллану кирәк, эш барышында музыка яңгырату, магнитофон, телевизор, компьютер куллану эшне тагын да җанландыра.

Түгәрәк эше балаларның күзаллавын киңәйтергә, аңа яңалык алып килергә, рухи тәрбия бирергә дә тиеш. Халык авыз иҗатын, татар халык педагогикасын куллану, табигать белән аралашу түгәрәк эшләрен оештырганда укытучыга зур мөмкинлекләр ача.

**Программаның эчтәлеге**

Татар театрының чишмә башы.Театрга нигез салучылар турында кыскача белешмә. Театр артистлары турында фикер алышу.

Татарстандагы театрлар. Театр артистлары турында белешмә. “ Сәхнә” журналын укып, анализлап бару.

“Сәйяр” труппасы,аны оештыручы Габдулла Кариев эшчәнлеге. Беренче татар хатын-кыз актрисасы С.Гыйззәтуллина-Волжская иҗаты.

Г.Камал һәм К.Тинчурин, - татар театрын оештыручылар.Аларның эшчәнлегенә күзәтү.
Галиәскар Камал исемендәге Татар дәүләт академия, Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия, Татар дәүләт Әкият курчак театр труппасы белән танышу

Г Камалның “Беренчк театр” пьесасын сәхнәгә кую.Видеоязмасын карау.Рольләрне бүлешү.Сәхнә бизәлеше өчен декорацияләр,костюмнар әзерләү.Репетицияләр үткәрү. Эти –эниләргә, бәйрәмнрдә тамашачыларга тәкъдим итү. “Син театр турында нәрсәләр беләсең?” темасына викторина уздыру.

“Шигъри сәхнә” исемле шигырьләрне сәнгатьле уку конкурсы уздыру.Р Корбанның “Куркуын җиңән куян” пьесалар китабы белән танышу.” Керпе малае дуслар эзли”исемле пьесасын сәхнәләштерү. К.Тинчурин исемендәге Татар дәүәт театрына экскурсия оештыру.

КАЛЕНДАРЬ – ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ

| № | Тема | Сәгать саны | Үткәрү вакыты | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | План | Факт | |
| 1. | Татар дөньясында беренче театр оешу, беренче “карлыгачлары” . | 1 сәг. | | | |
| 2. | Татар театрының чишмә башы. | 1 сәг. | | | |
| 3. | Татарстандагы театрлар. | 1 сәг. | | | |
| 4. | Театр артистлары турында белешмә. | 1 сәг. | | | |
| 5. | Габдулла Кариев һәм “Сәйяр” труппасы эшчәнлеге. | 1 сәг. | | | |
| 6. | Галиәсгар Камал, Кәрим Тинчурин – татар театрын оештыручылар. | 1 сәг. | | | |
| 7. | Галиәскар Камал исемендәге Татар дәүләт академия, Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры белән танышу. | 1 сәг. | | | |
| 8. | Курчак “Әкият” театры белән танышу. | 1 сәг. | | | |
| 9. | Татар драматурглары. | 1 сәг. | | | |
| 10. | Татар драматурглары. | 1 сәг. | | | |
| 11. | Г Камал иҗаты белән танышу | 1сәг. | | | |
| 12. | Г.Камалның “Беренче театр” комедиясеннән видеоөзек карау. | 1 сәг. | | | |
| 13. | Г.Камалның “Беренче театр” комедиясеннән видеоөзек карау. | 1 сәг. | | | |
| 14. | Г.Камалның “Беренче театр” комедиясеннән өзек сайлау | 1 сәг. | | | |
| 15. | Г.Камалның “Беренче театр” комедиясеннән өзекне ролләгә бүлү. | 1 сәг. | | | |
| 16. | Г.Камалның “Беренче театр” комедиясеннән өзекне рролләргә бүлеп уку | 8 сәг. | | | |
| 17. | Г.Камалның “Беренче театр” комедиясенә сәхнә бизәлешен карау | 2 сэг | | | |
| 18. | Г.Камалның “Беренче театр” комедиясенә рольләргә киемнәр барлау | 2 сәг. | | | |
| 19. | Г.Камалның “Беренче театр” комедиясенә музыкаль бизәлеш сайлау | 2 сәг. | | | |
| 20. | Г.Камалның “Беренче театр” комедиясен сәхнәгә тәкъдим итү | 1 сәг. | | | |
| 21. | Г.Камалның “Беренче театр” комедиясен видиога яздыру | 1 сәг. | | | |
| 22. | Т. Миңнуллинның иҗаты белән танышу. | 1 сәг.(каник) | | | |
| 23. | Т. Миңнуллинның балалар өчен язган әсәрләре белән танышу. | 1 сәг. | ноябрь | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 24. | Т. Миңнуллинның“Авыл эте Акбай” комедиясен уку. | 1 сәг. | | | |
| 25. | Т. Миңнуллинның“Авыл эте Акбай” комедиясен уку. | 1 сәг. | | | |
| 26. | Т. Миңнуллинның “Авыл эте Акбай” комедиясенең видеоязмасын карау. | 1 сәг. | | | |
| 27. | Т. Миңнуллинның “Авыл эте Акбай” комедиясенең видеоязмасын карау. | 1 сәг. | | | |
| 28. | Р Корбан иҗаты белән танышу | 1 сәг. | | | |
| 29. | Р.Корбан “Керпе малае дуслар эзли” пьесасын уку | 1 сәг | | | |
| 30. | Р.Корбан “Керпе малае дуслар эзли” пьесасын уку. | 1 сәг. | | | |
| 31. | Р.Корбан “Керпе малае дуслар эзли” пьесасын рольләгә бүлү | 1 сәг. | | | |
| 32. | Р.Корбан “Керпе малае дуслар эзли” пьесасын рольләп уку | 7 сәг | | | |
| 33. | Яңа ел бәйрәменә шигырьләр сайлау. | 2 сәг | декабрь | | |
| 34. | Яңа ел бәйрәменә җырлар, шигырьләр өйрәнү. | 3 сәг | | | |
| 35. | Яңа ел бәйрәменә җырлар, шигырьләр өйрәнү. | 3 сәг | | | |
| 36. | Яна ел тамашасы өйрәнү, киемнәр барлау, заллар бизәү | 7 сәг | | | |
| 37. | Яңа ел тамашасын сәхнәләштерү. | 1 сәг. | | | |
| 38. | Р.Корбан “Керпе малае дуслар эзли” пьесасын рольләп уку | 4 сәг | январь | | |
| 39. | Р.Корбан “Керпе малае дуслар эзли” пьесасына киемнәр сайлау | 3 сэг | | | |
| 40. | Р.Корбан “Керпе малае дуслар эзли” пьесасына музыка сайлау | 1 сәг. | | | |
| 41. | Р.Корбан “Керпе малае дуслар эзли” пьесасына сәхнә бизәлешен карау | 2 сәг. | | | |
| 42. | Р.Корбан “Керпе малае дуслар эзли” пьесасын сәхнәгә кую | 2 сәг. | | | |
| 43. | Р.Корбан “Керпе малае дуслар эзли” пьесасын видиога яздыру | 2 сәг. | | | |
| 44. | Сәнгатьле уку буенча эш. Әтиләр бәйрәменә шигырьләр ятлау. | 1 сәг. | февраль | | |
| 45. | Сәнгатьле уку буенча эш. Әтиләр бәйрәменә шигырьләр ятлау. | 1 сәг. | | | |
| 46. | Әти турында җыр өйрәнү. | 1 сәг. | | | |
| 47. | Әти турында җыр өйрәнү. | 1 сәг. | | | |
| 48. | Сәнгатьле уку буенча эш. Әтиләр бәйрәменә шигырьләр ятлау. | 2 сәг. | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 49. | Бәйрәмдә чыгыш ясарга әзерлек. | 1 сәг | | | |
| 50. | Бәйрәмдә чыгыш ясау. | 1 сәг | | | |
| 51. | Сәнгатьле уку буенча эш. Әниләр бәйрәменә шигырьләр ятлау. | 3 сәг | | | |
| 52. | Әни турында җыр өйрәнү. | 3 сәг | | | |
| 53. | Бәйрәмдә чыгыш ясарга әзерлек. | 3 сәг | | | |
| 54. | Бәйрәмдә чыгыш ясау. | 1 сәг | март | | |
| 55. | Р.Корбан “Куркуын җиңгән Куян” пьесасы белән танышу | 1 сәг. | | | |
| 56. | Р.Корбан “Куркуын җиңгән Куян” пьесасын рольләргә бүлү | 1 сәг. | | | |
| 57. | Р.Корбан “Куркуын җиңгән Куян” пьесасын рольләргә бүлеп уку | 1 сәг. | | | |
| 58. | Р.Корбан “Куркуын җиңгән Куян” пьесасы рольләгәбүлеп уку | 5 сәг. | | | |
| 59. | Сәхнә серләре. Мимика бирү юллары. | 1 сәг. | | | |
| 60. | Сәнгатьле уку буенча эш. | 2 сәг. | апрель | | |
| 61. | Р.Корбан “Куркуын җиңгән Куян” пьесасы рольләгәбүлеп уку | 1 сәг. | | | |
| 62. | Р.Корбан “Куркуын җиңгән Куян” пьесасына рольләргә киемнәр сайлау | 1 сәг | | | |
| 63. | Р.Корбан “Куркуын җиңгән Куян” пьесасына бию кую | 1 сәг | | | |
| 64. | Р.Корбан “Куркуын җиңгән Куян” пьесасына бию кую | 1 сәг | | | |
| 65. | Р.Корбан “Куркуын җиңгән Куян” пьесасына музыкалар сайлау | 1 сәг | | | |
| 66. | Р.Корбан “Куркуын җиңгән Куян” пьесасын сәхнәдә кабатлау | 1 сәг | | | |
| 67. | Сөйләм теленең культурасы | 1 сәг. | | | |
| 68. | Сөйләм теленең техникасы | 1 сәг. | | | |
| 69. | Сәхнә серләре. Мимика бирү юллары. | 1 сәг. | | | |
| 70. | Образларга керү, актерлык серләре белән танышу. | 1 сәг. | | | |
| 71. | Сәхнәдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре. | 1 сәг. | | | |
| 72. | Сәнгатьле уку буенча эш. | 1 сәг. | | | |
| 73. | Сәнгатьле уку буенча эш. Спектакль өстендә эш. | 1 сәг. | | | |
| 74. | Пьесаны сәхнәгә кую | 1 сәг. | | | |
| 75. | Җиңү көненә хәзерлек, шигырьләр сайлау. | 1 сәг. | май | | |
| 76. | Җиңү көненә җырлар кабатлау | 1 сәг. | | | |
| 77. | Сәнгатьле сөйләм өстендә эш. | 1 сәг. | | | |
| 78. | Сәнгатьле сөйләм өстендә эш. | 1 сәг. | | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 79. | Әсәрне тулысынча сәхнәләштерү. | 1 сәг. | | | |
| 80. | Әсәрне тулысынча сәхнәләштерү. | 1 сәг. | | | |
| 81. | .Сәхнәдә чыгыш ясауга әзерлек. | 1 сәг. | | | |
| 82. | Такмак әйтешле уеннар. | 1 сәг. | | | |
| 83. | Такмак әйтешле уеннар. | 1 сәг. | | | |
| 84. | Җитезлеккә уеннар өйрәнү. | 1 сәг. | | | |
| 85. | Җитезлеккә уеннар өйрәнү. | 1 сәг. | | | |
| 86. | Җитезлеккә уеннар өйрәнү. | 1 сәг. | | | |
| 87. | Татар халык бәйрәмнәре. | 1 сәг. | | | |
| 88. | Татар халык бәйрәмнәре. | 1 сәг. | | | |
| 89. | Тизәйткечләр. Санамышлар. | 1 сәг. | | | |
| 90. | Тизәйткечләр. Санамышлар.Тел шомарткычлар. | 1 сәг. | | | |
| 91. | Эшләгән эшләргә анализ. | 1 сәг. | | | |

**Укучылар өчен әдәбият**

1. “Мәктәп китапханәсе “ сериясеннән Татар классик драматургиясе  ТаРИХ- 2004
3.Әдәплелек дәресләре (хрестоматия). Фәнни редакторы профессор Р.А.Низамов. Казан: Мәгариф, 2000.
4. Балалар  сәхнәсе Рафис Корбан  “ Куркуын җиңән куян”2000.
5 Гөлбакча балалар өчен хрестоматия - 1990
6.Нәкый Исәнбәт “Балалар фолклоры” - 2023
.